| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 375

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат кертү регламентына теркәлгән 1 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә

органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 625 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат кертү регламентына теркәлгән 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (мәгълүмат килешүләр нигезендә бирелә) | | |
| | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы | 1. РФ нең ТР буенча дәүләт органнарында коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру буенча расланган программаларда (планнарда) күздә тотылган чараларны өстәмә финанслау булу (бар/юк).<br>2. Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары саны, әлеге өлкәдә 3 елдан артык эш тәҗрибәсе белән.<br>3. РФ дәүләт хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән, аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле булган вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче затларның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның, шулай ук аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы | 1. Коррупция юнәлешендәге җинаятьләр турында кергән хәбәрләр, шулай ук җинаять эзәрлекләве хакындагы мәсьәләне хәл итү өчен прокурор карарлары буенча җинаять эшләре кузгату турында кабул ителгән карарлар өлеше.<br>2. Хисап чорында кузгатылган җинаять эшләренең гомуми санына карата коррупция юнәлешендәге җинаятьләр буенча кузгатылган җинаять эшләре саны.<br>3. Коррупция юнәлешендәге җинаятьләр буенча кузгатылган, шулардан нигездә карау өчен судка җибәрелгән, башлангыч тикшерү стадиясендә туктатылган җинаять эшләре саны.<br>4. Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча суд законлы көченә кергән гаепләү карарлары чыгарган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларның дөрес һәм тулы булу-булмавына үткәрелгән тикшерүләр саны.<br>4. РФ дәүләт хезмәткәренең керемнәре, чыгымнары турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы, шулай ук ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларның дөрес һәм тулы булу-булмавына түбәндәгеләрдән алынган мәгълүматлар нигезендә үткәрелгән тикшерүләр саны:<br>хокук саклау органнарыннан;<br>коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплылардан;<br>сәяси партияләрдән һәм башка иҗтимагый берләшмәләрдән;<br>Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасыннан;<br>гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларыннан.<br>5. РФ дәүләт хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән, аларны биләү коррупцион куркынычлар белән бәйле булган вазыйфаларны биләүче РФ дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте | коррупция юнәлешендәге җинаятьләр буенча җинаять эшләре өлеше.<br>5. Суд законлы көченә кергән гаепләү карарлары, карарлар яки башка суд актлары чыгарган коррупция юнәлешендәге җинаятьләр буенча китерелгән зыянның бер җинаятькә исәпләнгән күләме.<br>6. Татарстан Республикасы территориясендә коррупция юнәлешендә җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затлар, шул исәптән закон чыгару хакимияте, башкарма хакимият, суд хакимияте органнарындагы, сайлау комиссияләрендәге, җирле үзидарә органнарындагы, хокук саклау органнарындагы һәм башка дәүләт органнарындагы вазыйфаи затлар саны.<br>7. Эшчәнлек өлкәләре (сәламәтлек саклау, мәгариф, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш, агросәнәгать комплексы, күчемсез мөлкәт белән эш итү, хәрби хезмәткә чакыру кампаниясе, башкасы) һәм җинаять турындагы законнар статьялары буенча коррупция юнәлешендә җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затлар саны |
| | Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәте- | һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар кертмәү йә алдан ук ялган, дөрес булмаган яки | |

<table>
<tr><td rowspan="5"></td><td>нең Идел буе идарәсе (Ростехнадзор)</td><td rowspan="5">тулы булмаган мәгълүматлар кертү очраклары саны.<br>6. РФ дәүләт хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән, аларны биләү коррупцион куркынычлар белән бәйле булган вазыйфаны биләүче РФ дәүләт хезмәткәренең ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар кертмәү йә алдан ук ялган, дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар кертү очраклары саны.<br>7. РФ дәүләт хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларның дөрес һәм тулы булу-булмавына тикшерүләр үткәрү өчен хокук саклау органнарына җибәрелгән материалларның гомуми саны, бу тикшерүләр нәтиҗәләре буенча кузгатылган эшләр санына карата.<br>8. Кабул ителгән норматив хокук актларының гомуми санында коррупциоген факторлар булу-булмау буенча коррупциягә каршы эчке экспертиза үткән, РФнең ТР буенча дәүләт органы тарафыннан эшләнгән норматив хокук актлар</td><td></td></tr>
<tr><td>Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсе</td><td>Россия Федерациясе милкендә булган мөлкәттән файдалану буенча үткәрелгән тикшерүләр саны, шулардан:<br>хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар санын күрсәтеп, нәтиҗәдә федераль законнарны бозуларны ачыклаган тикшерүләр саны</td></tr>
<tr><td>Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td>Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td>Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td>1. Тикшерүдә тоту буенча үткәрелгән чаралар саны:<br>РФнең ТР буенча дәүләт органнарының бюджет турындагы законнарны үтәвен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчыларның дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарны үтәвен;<br>заказчыларның, заказчылар-йортлар төзүчеләрнең төзелеш, рекон-</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | проектлары өлеше.<br>9. Прокуратура, юстиция органнары коррупциоген факторлар ачыклаган РФнең ТР буенча дәүләт органы эшләгән (раслаган) норматив хокук актлары саны.<br>10. Эксперт бәяләмәләрен һәм прокурорның чара күрү актларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган коррупциоген факторлар бетерелмәгән РФнең ТР буенча дәүләт органы норматив хокук актларының гомуми санына карата эксперт бәяләмәләрен һәм прокурорның чара күрү актларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган коррупциоген факторлар бетерелгән РФнең ТР буенча дәүләт органы норматив хокук актлары саны чагыштырмасы.<br>11. РФнең ТР буенча дәүләт органы рәсми сайтында, бәйсез экспертлардан бәяләмәләр кабул итә башлау һәм кабул итеп бетерү датасын күрсәтеп, норматив хокукый актлар проектлары булу (бар/юк).<br>12. РФ дәүләт хезмәткәрләре, шулай ук РФ нең ТР буенча дәүләт органында РФ дәүләт хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан башкарылган коррупцион хокук бозулар турында гражданнарның һәм оешмаларның теркәлгән мөрәҗәгатьләре саны, шул исәптән түбәндәге ысуллар белән:<br>язма мөрәҗәгать (почта аша);<br>кайнар линия («ышаныч те- | струкция, капиталь һәм агымдагы ремонт объектлары буенча бюджет акчасыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануын.<br>2. Тикшерүдә тоту буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган тәртип бозулар саны (ачыкланган тәртип бозуларның суммадагы чагылышын күрсәтеп):<br>РФ нең ТР буенча дәүләт органнарының бюджет турындагы законнарны үтәвен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчыларның дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарны үтәвен;<br>заказчыларның, заказчылар-йортлар төзүчеләрнең төзелеш, реконструкция, капиталь һәм агымдагы ремонт объектларында бюджет акчасыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануын.<br>3. Тикшерүдә тоту чаралары йомгаклары буенча кузгатылган административ эшләр саны:<br>РФнең ТР буенча дәүләт органнарының бюджет турындагы законнарны үтәвен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчыларның дәүләт ихтыяҗларын һәм муници- |

<table>
<tr><td rowspan="5"></td><td></td><td rowspan="5">лефоны»);<br>шәхсән кабул итү;<br>интернет-кабул итү;<br>массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмалар;<br>башкасы.<br>13. Хисап чорында кергән түбәндәге өлкәләрдә РФнең ТР буенча дәүләт органындагы коррупцион хокук бозулар турында гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре:<br>сәламәтлек саклау;<br>мәгариф;<br>торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш;<br>агросәнәгать комплексы;<br>күчемсез мөлкәт белән эш итү;<br>хәрби хезмәткә чакыру кампаниясе;<br>башкасы.<br>14. Сайтта, мәгълүмат стендында яки башка чыганакларда үзләренең хезмәт урыннарыннан файдалануга бәйле булган хокук бозулар өчен җаваплылыкка тартылган РФ нең ТР буенча дәүләт органы вазыйфаи затлары турында мәгълүмат булу (бар/юк).<br>15. РФ нең ТР буенча дәүләт органында үткәрелгән хокукый һәм коррупциягә каршы юнәлештәге чаралар саны, шул исәптән:<br>конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр», фәнни-гамәли семинарлар;<br>коррупциягә каршы тематика буенча белешмәлекләр, методик әсбаплар әзерләү;<br>РФ дәүләт хезмәткәрләренә коррупциягә каршы үз-үзләрен</td><td>паль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарны үтәвен.<br>4. Нәтиҗәсендә гамәлдәге законнарны бозулар ачыкланган лицензия-рөхсәт бирү эшчәнлеген алып бару тәртибе үтәлешен тикшерүдә тоту буенча үткәрелгән чаралар өлеше</td></tr>
<tr><td>Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td>Коррупция юнәлешендәге җинаятьләр өчен җәза алучы һәм дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләре булган Татарстан Республикасы халкы саны – барлыгы, шул исәптән:<br>ТР дәүләт органнарының;<br>РФ нең ТР буенча дәүләт органнарының;<br>җирле үзидарә органнарының</td></tr>
<tr><td>Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td>Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсенә караган Татарстан таможнясы</td><td></td></tr>
<tr><td>Дәүләт теркәве,</td><td></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td></td><td>кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td rowspan="6">тоту темасына консультацияләр;<br>коррупциягә каршы тематика буенча массакүләм мәгълүмат чараларында РФ нең ТР буенча дәүләт органы җитәкчесе (вәкиле) чыгышлары;<br>башка чаралар.<br>16. «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 ел, 9 февраль, ФЗ-8 нче Федераль закон таләпләре нигезендә мәгълүмат булу һәм РФ нең ТР буенча дәүләт органы сайтында, мәгълүмати стендларда һәм башка чыганакларда урнаштыру.<br>17. РФ нең ТР буенча дәүләт органы күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре саны.<br>18. РФ нең ТР буенча дәүләт органы сайтында һәм мәгълүмати стендта дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында мәгълүмат булу (бар/юк).<br>19. Юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын РФ дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бозу прецедентлары (нигезле шикаятьләр) булу (бар/юк).<br>20. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр буенча үткәрелгән сатып алулар саны, шул исәптән түбәндәге ысуллар белән:<br>конкурс;<br>аукцион;<br>котировкалар сорашу;</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автоюл күзәтчелеге идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенең Та-</td><td></td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тарстан Республикасындагы дәүләт хезмәт инспекциясе | тәкъдимнәр сорашу;<br>бердәнбер кайтартучыдан.<br>21. Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэ- | |
| | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе | мин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарда билгеләнгән таләпләр үтәлү, шулай ук лицензияләү-рөхсәт бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру (килештерү һәм теркәү процедураларын) буенча үткәрелгән тикшерүләр саны, шулардан:<br>хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар | |
| | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы | санын күрсәтеп, гамәлдәге законнарны бозулар ачыкланган тикшерүләр саны;<br>тәртип бозулар ачыкланган дәүләт контрактлары кыйммәтенең дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән алыш-бирешләрнең гомуми кыйммәтенә карата чагыштырмасы (мең сум)». | |

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\375.docx